КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 октябрь г.Казань № 960

«СМАРТ Сити Казан» технополисының китерә торган газ үткәргече» төбәк әһәмиятендәге газ белән тәэмин итү линияле объектын урнаштыру максатында ачык сервитутны билгеләү турында

«СМАРТ Сити Казан» технополисының китерә торган газ үткәргече» төбәк әһәмиятендәге газ белән тәэмин итү линияле объектын урнаштыру максатында Россия Федерациясе Җир кодексының V[7] бүлеге, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3[6] статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Лаеш муниципаль районы территориясендә «СМАРТ Сити Казан» технополисының китерә торган газ үткәргече» төбәк әһәмиятендәге линияле объектын урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне межалау проектын раслау турында» 2017 ел, 6 декабрь, 936 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте үтенече нигезендә «СМАРТ Сити Казан» технополисының китерә торган газ үткәргече» төбәк әһәмиятендәге линияле объектын урнаштыру максатында 1,5324 гектар гомуми мәйданлы җир кишәрлекләренә карата 10 елга ачык сервитут билгеләү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. »СМАРТ Сити Казан» технополисының китерә торган газ үткәргече» төбәк әһәмиятендәге линияле объектын урнаштыру максатларында ачык сервитут чикләренең урнашу урынының график тасвирламасын расларга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

ачык сервитут өчен түләүне исәпләү һәм кертү тәртибе Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{46}$ статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен куллану срогы, аларны рөхсәт ителгән куллану нигезендә мөмкин булмау яисә кыенлашу, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән гавами сервитут вакытына туры килә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына законнарда билгеләнгән тәртиптә әлеге карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

әлеге карарны муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгару өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә җибәрүне;

әлеге карарның күчермәләрен «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә ия булучыларга җибәрүне.

5. «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә ия булучылар белән гавами сервитутны гамәлгә ашыру турында килешүләр төзергә;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 елның 20 ноябрендәге 878 номерлы карары нигезендә, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән объектка карата сак зонасы чикләрен раслау турында гариза белән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына мөрәҗәгать итәргә;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә төзү-монтаж эшләрен 2020 елның IV кварталыннан 2022 елның IV кварталына кадәр һәм елга бер тапкыр планлы (регламент) эшләр башкарырга.

6. «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән куллану өчен яраклы хәлгә китерергә, гавами сервитут нигезендә урнаштырылган инженерлык корылмасын халыкка җиткерергә, эшчәнлекне тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{50}$ статьясында билгеләнгән срокларда төзергә.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин